# *Галиева Нурхәмия Салихҗан кызы*

*Мин, Галиева Нурхәмия Салихҗан кызы, 19 нче елның туганмын. Балачагым рәхәттә үтте дип әйтә алмыйм. Сугышның башлануы турында 1941 нче елның 22 нче июнендә ишеттем. Әтине сугышның беренче көнендә үк, аннан соң абыйны озаттык.1941 нче елны бик авыр үткәрдек. Әтисез калу бик авыр.*

*Сугыш авырлыкларын кичерергә әни булышты, һәрвакыт терәк булды. Күңел әрнегән вакытлар бик күп булды. Андый вакытларда еладык.*

*Бик авыр булды инде. Дәүәни дә булышты, сыер асрадык. Черек бәрәңге, тагын басуда нинди үлән бар, шуны ашадык. Фермада эшләдем, бозау карадым, шулай ук хат таратучы булып та эшләдем. Битаман мәктәбендә укыдым. Сугышчыларга ярдәм итеп булмады. Кораллар ясау өчен акча белән дә ярдәм итә алмадык.*

*Сугыш вакытындагы хезмәтебезне Дәүләт бәяләмәде. Сугыш бетү турында ишетеп мин дә, туганнарым да бик нык шатландык. Сугыштан җиңеп кайтучыларны куанып каршы ала идек.*

*Сугыштан соңгы елларда әйбәт яшәдек.*

*Хәзерге яшь буынга әйтәсе килгән теләкләрем: бәхетле тормышта исән-сау яшәсеннәр. Башка сугышлар булмасын иде.*